**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.07.2024 г. Казань № 1675

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 03.01.2023 елдагы 4 номерлы «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда юридик затларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрелә торган бәяләү битенең формасын раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 03.01.2023 елдагы 4 номерлы «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда юридик затларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрелә торган бәяләү битенең формасын раслау турында» боерыгына кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Бәяләү кәгазенең 7 бүлегендәге 9 пункты нигезләмәләре (әлеге боерык редакциясендә) 2024 елның 1 сентябреннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Министр М.М.Миңнуллин

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
18.07.2024 ел. № 1675
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 03.01.2023 елдагы 4 номерлы «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда юридик затларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрелә торган бәяләү битенең формасын раслау турында» боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1. 3 пунктта «В.В.Виниченкога» сүзләрен «В.С.Семеновка» дип алмаштырырга.
2. Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда юридик затларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрә торган бәяләү кәгазенең 7 бүлегендәге 9 пунктын яңа редакциядә бирергә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше буенча эшчәнлек алып бару нияте булган лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) җитәкчеләр составында наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше һәм (яки) наркотиклы үсемлекләрне культивацияләү өлкәсендә өстәмә һөнәри белеме булган белгеч бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктының «ж» пунктчасы (6 пунктның «э» пунктчасы) № 3-ФЗ Федераль законының 10 статьяның 1 пункты | | | | |